КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 июнь г.Казань № 429

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 3 июль, 534 нче; 2021 ел, 20 август, 750 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 951 нче; 2021 ел, 17 декабрь, 1245 нче; 2022 ел, 15 март, 239 нчы; 2022 ел, 13 июль, 673 нче; 2022 ел, 27 сентябрь, 1038 нче; 2023 ел, 11 февраль, 133 нче; 2023 ел, 22 июнь, 734 нче; 2023 ел, 8 сентябрь, 1114 нче; 2024 ел, 21 март, 171 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

егерме икенче абзацта «оешмаларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә» сүзләрен «икмәк пешерү предприятиеләренә» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җиләк һәм җимеш бирә торган күпьеллык куак үсентеләрен утыртуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган Мелиорация чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

түбәндәге эчтәлекле «$1^1$» пункт өстәргә:

«1[1]. Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән субсидия бирү юнәлеше буенча субсидия үз-үзен җайга сала торган оешмага керергә рөхсәте булган оешма тарафыннан төзелеш контролен уздыру шарты белән һәм төзелеш контролен гамәлгә ашыручы белгечләр Төзелеш өлкәсендәге белгечләрнең илкүләм реестрына кертелү шарты белән бирелә.»;

7 пунктның тугызынчы абзацына «, төзелеш контроле буенча хезмәт күрсәтүләргә шартнамә күчермәсен, башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре күчермәләрен» сүзләрен өстәргә;

11 пунктның икенче абзацында «чыгымнар» сүзе алдына «, төзелеш контроле буенча хезмәт күрсәтүләргә» сүзләрен өстәргә;

12 пунктның дүртенче абзацында «башкарылган эшләр» сүзләреннән соң «, төзелеш контроле буенча хезмәт күрсәтүләр» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Җитештерү куәтләрен модернизацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен икмәк пешерү предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 1 пунктындагы өченче абзацында «эшләнмәләр,» сүзеннән соң «икмәк пешерә торган он җитештерү өчен,» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Социаль икмәк җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен оешмаларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

исемендә «оешмаларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә» сүзләрен «икмәк пешерү предприятиеләренә» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип социаль икмәк җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле икмәк пешерү предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – сайлап алуда катнашучылар, субсидия) бирү (өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча) механизмын билгели.»;

җиденче абзацта «оешмаларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә» сүзләрен «сайлап алуда катнашучыларга» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның бишенче абзацында «4,5 сум» сүзләрен «6,0 сум» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктның унберенче абзацында «4,5 сум» сүзләрен «6,0 сум» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга Җиләк һәм җимеш бирә торган күпьеллык куак үсентеләрен утыртуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карарның 1 пунктындагы унтугызынчы һәм егерменче абзацларының гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 май, 397 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 15 июнь, 429 нчы карары редакциясендә)

## Җиләк һәм җимеш бирә торган күпьеллык куак үсентеләрен утыртуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип агымдагы финанс елында, шулай ук агымдагы финанс елына кадәрге елда тиешле субсидия бирелмәгән очракта, агымдагы финанс елына кадәрге елда җиләк һәм җимеш бирә торган күпьеллык куак үсентеләрен утыртуга бәйле сарыф ителгән чыгымнарның бер өлешен (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнарны тотып калып) каплау өчен авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия, сайлап алуда катнашучылар) бирү механизмын билгели.

2023 елда җиләк һәм җимеш бирә торган күпьеллык куак үсентеләрен утыртуга бәйле сарыф ителгән чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия бирелә, шул очракта, әгәр дә әлеге чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карары белән расланган Күпьеллык үсентеләрне утыртуга, карауга һәм тамыры белән чистартуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибе кысаларында капланмаган булса.

Өстәлгән бәягә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле салым түләүченең вазыйфаларын үтәүдән азат итү хокукын файдаланучы субсидия алучылар өчен чыгымнар өлешен каплау, өстәлгән бәягә салым суммасын да кертеп, әлеге пунктта күрсәтелгән максатларга чыгымнар суммасыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Тәртип максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

күпьеллык үсентеләр – көнбагыш, төшле, чикләвек, субтропик, җиләк куаклары утыртмалары (алга таба – җиләк һәм җимеш культуралары), колмак утыртмалары, шулай ук җиләк һәм җимеш куаклары культуралары питомниклары һәм колмак питомниклары;

питомник – күпьеллык үсентеләр, шул исәптән утырту материалы алу максатларында үстерелә торган җимеш һәм җиләк куаклары культураларының

аналык үсентеләре.

3. Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Үсемлекчелек ярдәмче тармагын үстерү, үсемлекчелек продукциясен эшкәртү һәм сату» төбәк проекты кысаларында бирелә.

4. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык).

5. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

6. Субсидия бирү алымы – чыгымнарны каплау.

7. Субсидияләр алучыларны сайлап алуны (алга таба – сайлап алу) үткәрү алымы – тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) соратып алу – сайлап алуны сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкаларның керү чиратыннан чыгып уздыру.

8. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башланган көнгә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

әлеге Тәртипнең 24 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 11 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм әлеге Тәртипнең 12 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 15 һәм 16 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) кул куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән тыелып калган (калганнар) дип тану шартларын;

Бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң була алмаган сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.

9. Субсидия алучы түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

үсемлекчелек продукциясен җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

10. Субсидия түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

субсидия алучылар тарафыннан күпьеллык үсентеләр утыртканда утырту материалы кулланылды:

сорт һәм чәчү (утырту) сыйфатлары күрсәткечләре «Орлык турында» 2021 елның 30 декабрендәге 454-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы билгеләгән авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыкларының сорт һәм чәчү (утырту) сыйфаты күрсәткечләренә карата таләпләргә туры килә (әгәр авыл хуҗалыгы үсемлекләренең төрләре авыл хуҗалыгы үсемлекләре төрләре исемлегендә булса);

сорт һәм чәчү (утырту) сыйфатлары күрсәткечләре ГОСТ Р 55758-2013, ГОСТ Р 70191-2022 һәм ГОСТ Р 59653-2021 туры килә (әлеге дәүләт стандартларының гамәлдә булуы кагылмый торган күпьеллык үсентеләр культураларыннан тыш) (авыл хуҗалыгы үсемлекләренең төрләре авыл хуҗалыгы үсемлекләренең төрләре исемлегенә кермәгән очракта);

күпьеллык үсентеләр утырту әлеге үсентеләр утырту проекты нигезендә башкарылды.

11. Сайлап алуда катнашучы заявка бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән дә артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре

капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булмау;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмау;

юридик зат булган сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау, ә индивидуаль эшмәкәр булган сайлап алуда катнашучы үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау.

12. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык боерыгы белән расланган рәвештә гариза, сайлауда катнашучының әлеге Кагыйдәләрнең 11пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүматны түләүле реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, «Интернет» челтәрендә сайлауда катнашучы турында, сайлауда катнашучы сайлап алуга гариза һәм башка мәгълүматны сайлап алуга, шулай ук персональ белешмәләрне (физик зат өчен) эшкәртүгә биргән мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) сайлауда катнашучының ризалыгын күрсәтү;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган өземтә йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт

реестрыннан Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтыннан гариза бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмәләр ( сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча салым органының салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәлеше турында заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага карата бирелгән, Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар һәм аны электрон рәвештә тапшыру форматының үтәлеше турында белешмә формасын раслау турында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча белешмәсен (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта Министрлык күрсәтелгән мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмә кәгазе;

күпьеллык үсентеләр утыртмалары биләгән җир кишәрлекләренә хокук билгели торган документлар күчермәсе;

агымдагы финанс елы һәм (яисә) агымдагы финанс елына кадәрге ел өчен 29-СХ номерлы форма (яисә 2-фермер номерлы форма буенча) хисап күчермәсе;

агымдагы финанс елы һәм (яисә) агымдагы финанс елына кадәрге ел өчен Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, мәйданын күрсәтеп, күпьеллык үсентеләр утырту акты күчермәсе;

күпьеллык үсентеләр утыртуга проект күчермәсе;

агымдагы финанс елында һәм (яисә) агымдагы финанс елына кадәрге елда төзелгән күпьеллык үсентеләр (питомникларны кертеп) утырту эшләрен башкаруга подряд шартнамәләре күчермәләре (подряд оешмасын җәлеп иткән очракта);

агымдагы финанс елы һәм (яисә) агымдагы финанс елына кадәрге ел өчен «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» КС-2 номерлы статистика формасы буенча белешмә кәгазенең күчермәсе;

агымдагы финанс елы һәм (яисә) агымдагы финанс елына кадәрге ел өчен «Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә кәгазе» КС-3 номерлы статистика формасы буенча белешмә кәгазенең күчермәсе;

агымдагы финанс елында һәм (яисә) агымдагы финанс елына кадәрге елда күпьеллык үсентеләр (питомникларны кертеп) утырту буенча башкарылган чыгымнарны раслый торган документлар (түләү йөкләмәләре, накладнойлар, счет-фактура һәм башка документлар) күчермәләре;

утырту материалының (үсентеләрнең) сорт сыйфатларының ГОСТ Р 55758-2013, ГОСТ Р 70191-2022 һәм ГОСТ Р 59653-2021 туры килү сертификаты күчермәсе.

Тапшырылган документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучы тарафыннан таныклана.

13. Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе

законнары нигезендә сайлап алуда катнашучы җаваплы була.

14. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка чират тәртибендә кергән көнендә теркәүгә алына.

15. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларны кабул итү срогы эчендә заявкаларны, керү тәртибе буенча аларның датасын һәм вакытын күрсәтеп, «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында терки;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән гаризалар кабул итү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә сайлап алуда катнашучыларны тикшерә һәм тапшырылган документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча сайлап алу нәтиҗәләре турында (сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү йә заявканы кабул итүдән баш тарту турында) реестр төзи һәм раслый;

сайлап алуда җиңүчеләр билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган сайлап алуда җиңүченең (җиңүчеләрнең) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

16. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик зат урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

заявканың сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 9 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитының сарыф итеп бетерелүе.

17. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән 15 эш көне эчендә субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешү төзи.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт.

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

18. Юридик зат булган субсидияне алучыны кушылу, кушу яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп төзегәндә, килешүгә, хокук варисы булган юридик затны килешүдә күрсәтеп, мәҗбүри рәвештә затны алмаштыру өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

Россия Федерациясе Граждан кодексының 23 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак эшчәнлекне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуар булган, үз хокукларын башка гражданга «Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә тапшыра торган субсидия алучының эшчәнлеге туктатылганда килешүгә, хокук варисы булган башка зат килешүендә якларны күрсәтеп, затны үзгәртү өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

19. Әлеге Тәртипнең 17 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә имза куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

20. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе.

21. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән килешүләр төзүне төгәлләү срогы көненнән бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән рәсмиләштерелә торган субсидия алучыларга субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

22. Субсидия бирелә торган җиләк-җимеш бирә торган күпьеллык үсентеләр утыртуга бәйле чыгымнарның юнәлешләре: утырту материалы, минераль, органик һәм биологик ашламалар, ягулык-майлау материаллары, пестицидлар һәм агрохимикатлар, шпалерлар, авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары, чыгым һәм төзелеш материаллары, боз сеткасы сатып алу, КС-2 формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән төзелеш, монтаж эшләре һәм эшләрнең башка төрләре (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнарны тотып калып).

23. Әлеге Тәртипнең 1 пункты ($W_з$) (сумда) нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_з = P_з \times 0,7,$$

монда $P_з$ – агымдагы финанс елында һәм (яки) агымдагы финанс елына кадәрге елда сарыф ителгән, әлеге Тәртипнең 22 пунктында күрсәтелгән җиләк һәм җимеш бирә торган күпьеллык үсентеләр утыртуга бәйле чыгымнар, сум.

24. Субсидия бирү нәтиҗәсе – субсидия бирү елының 31 декабренә күпьеллык үсентеләр утырту (питомникларны кертеп) мәйданы, гектар.

25. Субсидия алучы Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап, субсидия бирү елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, еллык хисап тапшыра.

26. Министрлык, күрсәтелгән хисап тапшырылган көннән алып 60 эш көненнән артмаган срокта, субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткече турындагы хисапны тикшерә.

27. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыручы вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

28. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

29. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган очракларда;

әгәр субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән булса, субсидия алучы субсидияне түбәндәге формула буенча билгеләнә торган күләмдә ($V_{кире\ кайтару}$) кире кайтаруны гамәлгә ашыра:

$$V_{кайтару} = (V_{субсидия} \times k),$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме, сум;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән күрсәткече;

S – субсидия алучы өчен килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча күрсәткече.

Субсидия акчасын кире кайтару күләме исәпләп чыгарылганда коэффициентның бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәү дәрәҗәсе чагылдырыла торган уңай мәгънәләре кулланыла.

30. Министрлык субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә почта аша, тапшыру турында хәбәр итү кәгазен теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, субсидия акчасын кире кайтару хакында хәбәрнамә җибәрә.

Әлеге Тәртипнең 29 пунктында күрсәтелгән акча Татарстан Республикасы бюджеты керемнә ирекле рәвештә кире кайтарылудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә 30 көн эчендә түләтелергә тиеш.